РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«26» апрель, 2024 ел Олы Кайбыч ав. №158

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законр, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Нигезләмәсенең 6нчы кушымтасында 4 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 15733 |

1.2. 7 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының 2020 елның
15 июнендәге 242 номерлы
карарына 7нче кушымта

**Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларны һәм Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт узучы (узган) затларны бер мәртәбә бүләкләү турында нигезләмә**

1. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләргә (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәттән азат ителгән Россия Федерациясе гражданнарына бүләкләүгә яисә акчалата бүләкләүгә тәкъдим ителгәннән соң, бер тапкыр бүләкләү түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

а) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы һәм Рәхмәт хаты белән бүләкләгәндә – муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладының 0,2 проценты күләмендә;

б) Татарстан Республикасы ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе бүләкләре белән бүләкләнгәндә - муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладының 0,3 проценты күләмендә;

в) Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Рәхмәт хаты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләгәндә – муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладының 0,5 проценты күләмендә;

г) Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре белән бүләкләнгәндә – муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладының 1,5 проценты күләмендә;

д) Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Хөкүмәте бүләкләре һәм Россия Федерациясе ведомство бүләкләре белән бүләкләнгәндә - муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең 1 вазыйфаи оклады күләмендә;

е) Россия Федерациясенең дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәре белән бүләкләнгәндә – муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең 2 вазыйфаи оклады күләмендә.

2. Бер тапкыр акчалата бүләкләү муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрнең Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы яисә муниципаль хокукый акт басылып чыгу датасына, ә гражданнарга карата аларны эштән җибәрү турында акт чыгарылган датага билгеләнгән вазыйфаи окладының күләменнән чыгып түләнә.

3. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка муниципаль хезмәткәргә яисә гражданга бер мәртәбә акчалата түләү күрсәтелгән зат муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган яисә биләгән Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль органы тарафыннан күрсәтелгән затны тиешле муниципаль орган хезмәте өчен түләү фонды акчалары исәбеннән бүләкләү турында хокукый акт басылып чыккан көннән соң 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка таратырга).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин